ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2021 г.Лениногорск № 983

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 августындагы 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан яңа редакциядәге муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 августындагы 1068 номерлы карары белән расланган бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны яшәү өчен яраксыз һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле торак йорт һәм бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре».

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләнә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72